**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ЗАРЕЧНЫЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

423008, РТ, Нурлатский район п. Заречный, ул. Черемшанская, д.5

Черемшанская ур., 5нче йорт, ТР, Нурлат районы, Заречный авылы, 423008

Телефон: 8 (84345) 38613, факс 38613 E-mail: Zarech.Nur@tatar.ru, сайт: http://nurlat.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Заречный п. **КАРАР**

«29» март 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Заречный поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 10 апрелендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлегендә Дорожная урамы 15 адресы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2024 елның 10 апрелендә 17 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Заречный торак пунктында Дорожная һәм Озерная урамнарында яшәүче гражданнар өчен Дорожная 24 адресы буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенын уздыру өчен Заречный поселогында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

4. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Заречный авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез гражданнар җыенында элек расланган мәсьәләләргә үзгәрешләр кертүгә ризамы;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлегенең Заречный поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 17 октябрендәге 1 номерлы карары»

Аны түбәндәге редакциядә расларга:

«Нурлат муниципаль районы Заречный авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү ризамы:

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

торак пункт территориясен төзекләндерү;

« РИЗА» «КАРШЫ».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына http://nurlat.tatarstan.ru урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Заречный авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Заречный авыл җирлеге башлыгы Т.В Забойдулина